**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ _________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2018-2019 еллардагы көзге-кышкы чорда халыкның иминлеген тәэмин итү һәм су объектларында һәлак булучыларны профилактикалау чаралары турында

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы буенча комиссия рәисенең 08.10.2018 елның, 26-18р номерлы «2018-2019 елларның кышкы чорында Татарстан Республикасы халкының су объектларында куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында» гы боерыгы нигезендә, кышкы чорда су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өчен шартлар тудыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1 «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары, Татарстан Республикасы су объектларында боз кичүләреннән файдаланганда кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү турында боерыклар үтәлешен тәэмин итәргә:

- кышкы балык тоту максатларында кешеләрнең массакүләм чыгу урыннарын ачыкларга һәм исәпкә алырга; республика ОСВОД территориаль бүлекчәләреннән гражданнарның бозга массакүләм чыгу урыннарында кизү тору һәм бозлар калу чорында булган хәлләргә җавап бирү өчен җаваплы затларны билгеләргә;-
- гражданнарның бозга массакүләм чыгу урыннарында патрульлек итү өчен мобиль патруль төркемнәре төзергә;
- бу елның 5 ноябреннән мобиль патруль төркемнәре эшен оештырырга;

2. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2018-2019 елларның көзге-кышкы чорында халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм һәлак булуын профилактикалау» комиссиясе составын 1.2.1 кушымта нигезендә расларга. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2018-2019 еллардагы көзге-кышкы чорда халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм һәлак булуын профилактикалау» комиссиясенә»:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 23.04.2014 ел, № 256 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 8.4 пункты нигезендә, әлеге норманы бозу фактларын ачыклаганда, гражданнарны Татарстан Республикасы КоАП 3.10 статьясы нигезендә (8 статья нигезендә) административ җаваплылыкка тартырга.Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексына үзгәрешләр кертү турында (2015 елның 25 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законы редакциясендә); башкарма хакимият органнарының территориаль бүлекчәләре һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итүдә катнашучы оешмалар вәкилләре белән берлектә профилактик чаралар үткәрергә; бозның интенсив эрүе чорында, яшәү өчен куркыныч булган транспорт чаралары бозларына рөхсәт ителмәгән боз кичүләрен булдырмау чаралары комплексын тормышка ашырырга; Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең су объектларында кешеләрнең иминлеге бүлегенә муниципаль районнарның ЕДДС аша донесениеләр кертүне оештырырга:

кышкы балык тоту өчен кешеләр күпләп җыела торган урыннар исемлеге (2018 елның 1 ноябренә кадәр):

КЧС һәм муниципаль берәмлекнең ОПБ утырышы карары күчермәсе (2018 елның 1 ноябренә кадәр); 5 ноябрьдән (бозлыклар башлангач) мобиль эшче төркемнәр эшен оештырырга; агымдагы елның 5 ноябреннән 2019 елның 20 апреленә кадәр килеп туган хәл һәм беркетелгән форма буенча башкарылган чаралар турында.

Татмедиа ААҖ филиалы"Актаныш мәгълүмат-мөхәррият үзәге" директорына халыкка су объектларында килеп туган боз торышы һәм кешеләрнең куркынычсыз үз-үзен тотышы турында мәгълүмат җиткерүне оештырырга

Авыл җирлекләре башлыкларына теркәлмәгән боз кичүләрен ачыклау һәм алардан файдалануга юл куймау буенча кирәкле чаралар күрү эшен оештырырга:

-аларга керү юлларын (ябарга); автотранспортка чыгуны һәм кешеләрнең бозга чыгуын тыю турындагы мәгълүмат белән аншлаглар урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль
районы Башкарма
комитет карарына
____________ №___
кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 20l8-2019 еллардагы көзге-кышкы чорда халыкның иминлеген тәэмин итү һәм һәлак булуын профилактикалау комиссиясе составы

Комиссия рәисе:
Бариев И.Ш. муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе;

Комиссия рәисенең беренче урынбасары:
И.И. Шәрифьянов Актаныш янгын сүндерү-коткару гарнизоны башлыгы (килешү буенча);

Р.В.Хөсәенов «Актаныш муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе» МКУ җитәкчесе;

Комиссия әгъзалары:
Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча);

Нургалиев И.И. Актанышның ОСВОД җитәкчесе (килешү буенча):

Хәйретдинов ИМ. -Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Мансуров А.М. Социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Нафикова Н.Р. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы (килешү буенча);
Усманов Р.М.«Актаныш мәгълүмат-редакция үзәге» ААҖ филиалы директоры (килешү буенча).